КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 декабрь г.Казань № 1149

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 31 декабрь, 1097 нче карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы

нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 31 декабрь, 1097 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 10 июнь, 393 нче; 2014 ел, 6 декабрь, 955 нче; 2015 ел, 3 октябрь, 739 нчы; 2017 ел, 27 октябрь, 813 нче; 2017 ел, 22 декабрь, 1021 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1269 нчы; 2019 ел, 1 ноябрь, 994 нче; 2020 ел, 15 октябрь, 930 нчы; 2021 ел, 30 декабрь, 1348 нче; 2022 ел, 9 март, 211 нче; 2022 ел, 19 сентябрь, 1017 нче; 2024 ел, 13 май, 321 нче; 2024 ел, 7 октябрь, 863 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «12. | 112 нче хезмәтнең психологик ярдәм бүлеге башлыгы | 47 778 | 46 008 | 44 265 | 42 642»; |

4 нчы таблицада:

24 пунктка түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| | «112 нче хезмәтнең психологик ярдәм бүлеге психологы | 37 751»; |

34 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «34. | 112 нче хезмәтнең ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча белгече: | |
| | 112 нче хезмәтнең ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча баш белгече | 43 329 |
| | 112 нче хезмәтнең ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча төп белгече | 40 724 |
| | 112 нче хезмәтнең ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча өлкән белгече | 39 222 |
| | 112 нче хезмәтнең ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча белгече | 37 751». |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин